ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
БАВЛИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БАУЛЫ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

17.06.2025 ел Баулы шәһәре № 76

Баулы муниципаль районы Башкарма комитетының 2024 елның 7 ноябрендәге 157 номерлы «Баулы муниципаль районы муниципаль мәгариф оешмаларында башлангыч гомуми белемнең уку-укыту программалары буенча укучыларны түләүсез кайнар туклану белән тәэмин итүгә 2025 елга, 2026 һәм 2027 еллар план чорына норматив чыгымнарны һәм башлангыч гомуми белемнең уку-укыту программалары буенча укучыларны кайнар тукылануның уртача хакын раслау турында» карарына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2025 елның 21 апрелендәге 253 номерлы «Татарстан Республикасы дәүләт мәгариф оешмаларында башлангыч гомуми белем бирүнең белем бирү программалары буенча укучыларны түләүсез кайнар тукландыруны оештыруга һәм тәэмин итүгә норматив чыгымнарны һәм 2025 елга һәм 2026 һәм 2027 еллар план чорына белем алучыларның башлангыч гомуми белем бирү программалары буенча кайнар тукылануының уртача бәясен раслау турында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2024 елның 12 сентябрендәге 777 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында» карары нигезендә, Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР ИТӘ:

1. Баулы муниципаль районы Башкарма комитетының 2024 елның 7 ноябрендәге 157 номерлы «Баулы муниципаль районы муниципаль мәгариф оешмаларында башлангыч гомуми белемнең уку-укыту программалары буенча укучыларны түләүсез кайнар туклану белән тәэмин итүгә 2025 елга, 2026 һәм 2027 еллар план чорына норматив чыгымнарны һәм башлангыч гомуми белемнең уку-укыту программалары буенча укучыларны кайнар тукылануның уртача хакын раслау турында» карарына түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1 нче «2025 елга, 2026 һәм 2027 еллар план чорына Баулы муниципаль районы муниципаль мәгариф оешмаларында башлангыч гомуми белем бирү программалары

буенча укучыларны түләүсез кайнар ризык белән тәэмин итүгә норматив чыгымнар» кушымтасында «69,43» саннарын «74,77» саннарына алмаштырырга.;

2 нче «2025 елга, 2026 һәм 2027 еллар план чорына белем алучыларның кайнар туклануының уртача бәясе» кушымтасында «69,43» саннарын «74,77» саннарына алмаштырырга.

2. 2. Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (http://www.pravo.tatarstan.ru) һәм Баулы муниципаль районы сайтында (http://www.bavly.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарның гамәлдә булуы 2025 елның 1 апреленнән барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла дип билгеләргә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Баулы муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча беренче урынбасарына йөкләтергә.

Баулы муниципаль районы
Башкарма комитеты җитәкчесе Д.Л. Бакиров